**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының**
**Чалпы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чалпы авылы № 126 28 ноябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Советы «Чалпы авыл җирлеге» территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карар проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чиста һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатларында,

Чалпы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының “Чалпы авыл җирлеге” территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” кабул ителә торган карар проектын (18.03.2014 № 97, 19.08.2014 № 118, 25.08.2017 №65) хупларга. (кушымта №1)

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Советы «Чалпы авыл җирлеге» территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карар проекты турында гавами тыңлауларны үткәрергә.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты - 2018 елның 09 декабреннән 2019 елның 11 гыйнварына кадәр;

- үткәрү урыны - Чалпы авылы, Үзәк ур., 24, ;

- 2019 елның 11 гыйнварына кадәр - Чалпы авылы, Үзәк урамы, 39 йорт, Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге башкарма комитеты язма тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертелергә мөмкин (эш көннәрендә 8.00 дән

17.00 сәгатькә кадәр (төшке ашка тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

4. Катнашкан гавами тыңлаулар үткәрү буенча эшче төркем төзергә:

- Мөхәммәтшин А.М. - Чалпы авыл җирлеге башлыгы;

-Гәрәев А.С. - Чалпы авыл җирлегенең 7 нче округы депутаты;

Габидуллин И.З. -Чалпы авыл җирлегенең 10 нчы округ депутаты

5. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының “Чалпы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карар проекты буенча халык алдында тыңлаулар уздыруны тәэмин итәргә, гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итәргә һәм исәпкә алырга (2014 елның 18 мартындагы 97нче, 19 августындагы 118 номерлы, 2017 елның 25 августындагы 65 номерлы карарлар редакциясендә).

6. Торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссия гавами тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, чираттагы утырышны карауга кертергә тиеш.

7. 2018 елның 04 декабреннән дә соңга калмыйча, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: А. М. Мөхәммәтшин

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Советының 2018 елның 28 ноябрендәге 126 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының**
**Чалпы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чалпы авылы №___ __ _________ 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2013 еның 24 декабрендәге 87 номерлы Чалпы авыл җирлеге советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (18.03.2014 №97, 19.08.2014 №118, 25.08.2017 №65 карарлар редакциясендә)»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 463-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чиста һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатларында,

Чалпы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2013 еның 24 декабрендәге 87 номерлы Чалпы авыл җирлеге советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә (18.03.2014 №97, 19.08.2014 №118, 25.08.2017 №65 карарлар редакциясендә)» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«территорияне төзекләндерү - гражданнарның яшәү шартларының уңайлылыгын тәэмин итүгә һәм арттыруга, муниципаль берәмлек территориясенең санитария һәм эстетик торышын яхшыртуга, торак пунктлар һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектлар территорияләрен, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, корылмаларны, якын территорияләрне карап тотуга юнәлдерелгән әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру эшчәнлеге;»

б) түбәндәге эчтәлекле унҗиде абзац өстәргә:

«төзекләндерү элементлары - территорияне төзекләндерүнең состав

өлеше буларак кулланыла торган декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җиһазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре, шул исәптән биналарның, корылмаларның фасадлары, кече архитектур формалары, капиталь булмаган стационар корылмалар һәм корылмалар, мәгълүмат такталары һәм күрсәткечләр.».

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 7.17 пункт белән тулыландырырга:

«7.17. Йорт билгеләрендәге, тышкы мәгълүмат чараларындагы мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы законнар таләпләрен үтәгән килеш урнаштырылырга тиеш. Ике яки аннан да күбрәк тел кулланган очракта, текстлар эчтәлек һәм техник бизәлеш буенча тиңдәш булырга, грамоталы һәм аңлаешлы итеп башкарылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.